КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 март г.Казань № 227

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 июль, 548 нче; 2015 ел, 26 май, 378 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1024 нче; 2016 ел, 30 сентябрь, 697 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1082 нче; 2018 ел, 26 апрель, 298 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгын» сүзләренә алыштырырга;

3 пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

4 пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

9 пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бу карар 2019 елның 31 декабренә кадәр (2019 елның 31 декабрен кертеп) гамәлдә була».

11 пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасында (алга таба – Программа):

Программа паспортында:

«Программа бурычлары» юлын түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты мирасы концепциясен тормышка ашыру»;

«Программаны гамәлгә ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны гамәлгә ашыру вакытлары | 2013 – 2019 еллар»; |

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләме 4 543,0 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән 2 064,0 млн.сумы – федераль бюджет акчасы, 2 343,2 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 135,8 млн.сумы – бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән. |

(млн.сум)

| Ел | Программа буенча финанслау күләме барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе бюджеты акчасы | Җирле бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2013 | | | | | |
| 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |
| 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| 2016 | 1 203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| 2017 | 1 411,3 | 524,3 | 887,0 | | |
| 2018 | 1 610,6 | 1 092,4 | 518,2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2019 | 135,0 | 6,8 | 128,2 | | |
| Всего | 4 543,0 | 2 343,2 | 2 064,0 | | 135,8»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН НИГЕЗЛӘҮ

Программаны финанслау күләме 4 543,0 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән 2 064,0 млн.сумы – федераль бюджет акчасы, 2 343,2 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 135,8 млн.сумы – бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән.

(млн.сум)

| Ел | Программа буенча финанслау күләме барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федера-циясе бюджеты акчасы | Җирле бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2013 | | | | | |
| 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |
| 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| 2016 | 1 203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| 2017 | 1 411,3 | 524,3 | 887,0 | | |
| 2018 | 1 610,6 | 1 092,4 | 518,2 | | |
| 2019 | 135,0 | 6,8 | 128,2 | | |
| Барлыгы | 4 543,0 | 2 343,2 | 2 064,0 | | 135,8 |

Программаның фаразлана торган ресурслар белән тәэмин ителеше аңа теркәлгән 1 нче кушымтада бирелә.»;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин